**ГЛАВА**
**БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422640, с. Большая Елга,
ул.Октябрьская, дом 25

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ ЕЛГА**
**АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

422640, Олы Елга авылы,
Октябрь урамы, 25 йорт

Тел.: (84361) 25-264, факс: (84361) 25-265, эл.адрес: Belg.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 1 ноябре Олы Елга авылы № 4

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Кама поселогы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Кама поселогы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 14 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Кама поселогы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган, көндез укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре, һәр кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыйналган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга Сез ризамы?

- урамнарны яктырту җайланмалары урнаштыру;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

«ЯКЛАП» «КАРШЫ».

3.Әлеге карарны кабул ителгәннән соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам,16А йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ш.Сайфутдинов